| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.05.2018 г.Казань № 367

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 1 июнендә теркәлде, № 4718

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы белән расланган Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 40-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия

Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 11.07.2016 № 395, 28.11.2016 № 668, 08.06.2017 № 349 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
15.05.2018 № 367 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы белән расланган «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.4.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Үзәк) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.»;

1.4.2 пунктның 2, 3, 4 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(mtsz@tatar.ru).»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«1.5. Хезмәт түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр түләү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр түләү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 1-2, 0018 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә һәм айлык акчалата түләүләр түләүгә субсидияләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 5, 0156 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр

кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Банкта яисә башка кредит учреждениесендә ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза.<br>2. Гариза тапшыру алдыннан килгән алты ай өчен дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан алынган керемнәр турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында алар турында белешмәләр булган түләүләрдән һәм Россия ЭЭМ, Россия Оборона министрлыгы түли торган пенсияләрдән тыш) документлар, шул исәптән:<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында:<br>хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы турында;<br>дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында;<br>эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына | Нигезләмәнең<br><br>9.1 п. »; |

| | | |
|---|---|---|
| | саклана торган хезмәт хакы турында;<br>Россия Федерациясенең граждани законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү турында;<br>эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында;<br>барлык дәрәҗәдә бюджетлардан социаль түләүләр турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, кушып түләүләр) турында;<br>пенсионерларны өстәмә ай саен матди тәэмин итү турында;<br>ихтыяри иминиятләштерү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр турында, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп;<br>отставкага киткән судьяларга ай саен түләнә торган гомерлек тәэминат турында;<br>оешмалар белән найм шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы, бала карау буенча отпускта булган гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләүләре турында.<br>Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен белдерүгә үзләренең вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза кәгазенең электрон формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:<br>барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды); | Нигезләмәнең 9.2 п.,<br>Нигезләмәнең 9.10 п. |

| | | |
|---|---|---|
| бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (Россия Федерациясе Пенсия фонды);<br>пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында (Россия ЭЭМ);<br>хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында (Россия Оборона министрлыгы);<br>житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды);<br>эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (мәшгульлек үзәкләре);<br>дәүләт хезмәтен алучы балигълык яшенә җитмәгән зат булган очракта, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен тууны дәүләт теркәвенә алу турында (ГХАТ органнары);<br>дәүләт хезмәтен алучы балигълык яшенә җитмәгән зат булган очракта, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнары);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият | |

| | | |
|---|---|---|
| | номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан).<br>Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр полртaлы аша яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәт Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткәндә өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:<br>мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында);<br>яшәгән урыны буенча алучының теркәүгә алынуының чын булуын раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында).<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагында булган | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш. | |

2.15 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п.,<br>601 номерлы РФ Президенты указының 1 п. » |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәт Инфоматларында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта буенча, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәт Инфоматларыннан җибәргән очракта турыдан-туры бәйләнешкә кереп эш итү таләп ителмәячәк. | |

2 бүлек таблицасында 2.13 пунктның 2 графасында түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә»;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Айлык акчалата түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына барлык дәрәҗә бюджетлардан иминиятләштерелгән затка социаль түләүләр күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

Россия Эчке эшләр министрлыгына пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең тәмамлануы турында;

Россия Оборона министрлыгына хәрби хезмәткәрләр ала торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында;

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларны дәүләт теркәвенә алу турында, ГХАТ органнарына;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында җирле үзидарә органнарына;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында җирле үзидарә органнарына;

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса;

алучының гаризада күрсәтелгән яшәгән урыны буенча теркәүгә алынуының чын булуын раслау турында – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша җибәрелгән булса.

Әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган һәм «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның «Социаль ярдәм чаралары» өлешенә кертелгән белешмәләр, белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.1. Үзәк бүлегендәге хезмәткәрләрнең Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибе һәм рәвешләре Үзәк директоры тарафыннан билгеләнә.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) (алга таба – Идарә (бүлек)) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

белешмәләрне һәм документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

гаризаларны һәм документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә яисә Идарә (бүлек) җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәтне күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение хезмәткәре) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның дәүләт хезмәткәренең, җитәкчесенең гамәл кылу карарына (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять югары торучы органга (андый булган очракта) бирелә яисә, андый булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры карала.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән

файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталынан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, анын

ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.»;

5.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

РМЯ(КТ)Ү бүлеге №_____

________________________________

муниципаль районында (шәһәрендә)

ГАРИЗА № _______

20____ елның «__» _________

Мин,____________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ аталышы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:

______________________________________________________________________________,

(индексын күрсәтеп мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

түбәндәгегә нигезләнеп гамәл кылучы:________________________________________
______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш йөртү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләүне сорыйм
_________________________________________________________________________.
(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

СНИЛС (алучыныкы)__________________________________________
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:
счет реквизитлары ____________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә) почта бүлеге реквизитлары
______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучының яисә аның законлы вәкиленең почтадан җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең төгәл булуы, шулай ук аларны үз эченә алган документларның хаклыгы өчен җаваплы булам. Социаль ярдәм чараларын түләүгә йогынты ясаучы шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында нигезләмә белән таныштым.

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза (кирәклесе астына сызарга):
язмача, телефон буенча, смс-хәбәр белән, электрон почтадан, ТР ДМХП шәхси кабинет аша

«__» __________ 20__ ел. Имза ______________________
(гариза бирүченең имзасы)

Эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан минем файдага түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында Россия Федерациясе Пенсия фондында социаль ярдәм чараларын билгеләү буенча мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 6 ай һәм 12 ай өчен булган белешмәләр нигезендә социаль ярдәм чаралары билгеләнүгә риза.

Гариза бирүченең имзасы ____________________

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________

______________________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

---

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_______

Документлар саны _____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ____________ _________ _______________ ______ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)».